КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче
Иске Икшермә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

12.11.2024 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү 2024 нче елның 12 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Иске Икшермә торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Иске Икшермә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә тезелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын тезү, ремонтлау, карап тоту (Иске Икшермә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 324 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 183 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның 183 е тавыш бирде;
- «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Иске Икшермә торак пунктында гражданнар җыенын үткән дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.

2. «2025 нче елда Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Иске Икшермә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә» һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын тезү, ремонтлау, карап тоту (Иске Икшермә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау)» - дигән сорауны кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Иске Икшермә

авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенында рәислек итүче,
Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы: А.И.Биккинин